КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 апрель г.Казань № 233

Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында

Язгы-җәйге чорда янгын чыгу куркынычы дәрәҗәсе артуга бәйле рәвештә, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 22 апреленнән 12 маена кадәр Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләргә.

2. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булу чорында түбәндәгеләрне тыяра:

учаклар кабызу, каты көнкүреш калдыкларын, коры үлән һәм чүп-чарларны яндыруны;

урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигать) янгыннары чыгу куркынычына дучар булган торак пунктларда, урман янгыннары чыгу куркынычына дучар булган балалар ялы һәм аларны савыктыру оешмалары территорияләрендә, гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек (алга таба – бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте) алып бару территорияләрендә, шулай ук урман массивлары белән чиктәш икътисад объектларында азыкны янмый торган махсус савытларга (мангал, тимер учакларга һ.б.ш.), җылылык белән азык эшкәртелә торган башка җайланмаларга (җәмәгать туклануы объектлары (рестораннар, кафе, барлар һ.б.ш.) территорияләрендә урнашкан һәм файдаланыла торган мангаллардан һәм башка җайланмалардан тыш) салып әзерләү өчен ачык ут куллануны;

урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигать) янгыннары чыгу куркынычына дучар булган торак пунктларда, балалар ялы һәм аларны савыктыру оешмалары территорияләрендә, бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләре

территорияләрендә, савыктыру оешмаларында, шулай ук икътисад объектларында, урман-парк зоналарында, торф участокларында һәм урман массивлары белән чиктәш ачык территорияләрдә 1 – 3 куркынычлылык классларындагы пиротехника эшләнмәләре куллануны;

конструкция эчендәге һава ачык ут белән җылынып, биеклеккә күтәрелә торган, яна торган материаллардан эшләнгән, идарә ителми торган эшләнмәләрне очыртып җибәрүне.

3. Республика башкарма хакимият органнарына:

ведомство буйсынуындагы объектлар территорияләрен коры үләннән һәм чүп-чардан чистарту буенча чаралар күрергә;

баланстагы янгын сүндерү өчен кулланыла торган тышкы су белән тәэмин итү чыганакларының эшкә яраклылыгын тикшерергә;

янгынга каршы махсус режим гамәлдә булу чорында янгын чыгара торган эшләрне башкаруны чикләргә.

4. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

янгынга каршы превентив профилактик чаралар комплексын планлаштыруны һәм үткәрүне;

массакүләм мәгълүмат чараларында торак пунктларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча катлаулы мәсьәләләрне яктыртуны, шулай ук халыкка янгын чыгу куркынычы сезонында янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүмат бирүне.

5. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә:

башкарма комитетлар җитәкчеләренә, бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләре рәисләренә, балалар ялы һәм аларны савыктыру оешмалары җитәкчеләренә урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигать) янгыннары чыгу куркынычына дучар булган торак пунктларның, урман янгыннары чыгу куркынычына дучар булган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләре территорияләренең, балалар ялы һәм аларны савыктыру оешмаларының паспортларын эшләүдә (актуальләштерүдә) консультация һәм методик ярдәм күрсәтүне;

торак пунктларны, бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, икътисад объектларын урман янгыннарыннан һәм башка ландшафт (табигать) янгыннарыннан саклауны контрольгә алуны, шулай ук урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигать) янгыннары чыгу урыннарын үз вакытында ачыклау һәм аларны ачыклаган көнне бетерү эшен оештыруны;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федераиясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карарын исәпкә алып, корыган үләннәрне яндыру тәртибен аңлату эшен оештыруны;

урман янгыннары чыгу куркынычына дучар булган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләре рәисләре белән янгын куркынычсызлыгы чаралары буенча киңәшмәләр үткәрүне;

космостан мониторинглау чаралары ярдәмендә ачыкланган янгыннар (термик нокталар) турындагы сигналларга үз вакытында чара күрүне тәэмин итүне;

Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә, «Түбән Кама» милли паркы һәм Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгы җитәкчеләренә:

янгын чыгу куркынычы сезоны башланганга кадәр урман янгыннарын сүндерә торган махсуслаштырылган техниканы һәм җайланманы төзек хәлгә китерүне, махсус сакланыла торган табигать территорияләре чикләрендә янгынга каршы профилактик чаралар комплексын үз вакытында үтәүне тәэмин итүне;

республика җирле үзидарә органнарына торак пунктларның урман массивлары янындагы чикләре буйлап минераллаштырылган полосалар урнаштыруда ярдәм күрсәтүне;

һәр янгын чыгу факты турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына ашыгыч рәвештә бирүне;

Горький тимер юлының Казан бүлегенә – «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалына янгын чыгу куркынычы сезоны башланганга кадәр тимер юллар өчен бүлеп бирелгән полосаларда янгынга каршы профилактик чаралар комплексын үз вакытында үтәүне тәэмин итүне, шулай ук тимер юллар өчен бүлеп бирелгән полосаларда янгын чыгу очраклары турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына ашыгыч рәвештә бирүне;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына:

урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигать) янгыннары чыгу куркынычына дучар булган торак пунктларда вакытлыча янгын сүндерү постларын оештыруны;

торак пунктларны янгыннан саклауны ныгытуга юнәлдерелгән, шул исәптән чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны, материал һәм әйберләрне яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү буенча муниципаль хокукый актлар кабул итүне;

корыган үләннәрнең үсми торган урыннарын ачыклау, шулай ук янгын чыгу урыннарына карата кичектергесез чара күрү максаты белән һәр авыл җирлегендә контрольдә тотучы патруль төркемнәрен булдыруны һәм аларның эшен оештыруны, әлеге төркемнәрнең эш графикларын эшләүне һәм янгын чыгу куркынычы сезоны башланганга кадәр аларны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына кертүне;

халык белән янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү һәм торак пунктлар, бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләре территорияләрендә янгын чыкканда эш итү гамәлләре тәртибе буенча аңлату эшләрен алып баруны планлаштыруны һәм үткәрүне, бу юнәлештә массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлекне оештыруны;

янгын чыгу куркынычы сезоны башланганга кадәр торак пунктларны һәм

икътисад объектларын урман янгыннарыннан һәм башка ландшафт (табигать) янгыннарыннан саклау өчен минераллаштырылган полосалар булдыруны, территорияләрне, бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләре территорияләрендәге хуҗасыз һәм озак вакыт файдаланылмый торган җир кишәрлекләрен корыган үлән, чыбык-чабык, чүп-чардан һәм башка ягулык материалларыннан чистарту эшләрен тәмамлауны;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләре утырышларында торак пунктларның янгын куркынычсызлыгы торышы һәм янгын куркынычсызлыгы буенча күрелә торган беренче чараларны гамәлгә ашыру турындагы мәсьәләләрне карап тикшерүне;

янгын сүндерү автомобильләре белән су алу өчен табигый һәм ясалма сулыкларны һәм аларга керү юлларын төзек хәлдә тотуны тәэмин итүне;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системаның муниципаль звенолары көчләре һәм чаралары табигать янгыннарын сүндерүгә әзерлеген тикшерүне;

урманнарда янгын чыгу торышы катлаулану чорында ихтыяри һәм муниципаль янгын сүндерү хезмәте әгъзаларының тәүлек буе кизү тору планнарын, шулай ук су сиптерү һәм янгын сүндерү өчен җайлаштырылган башка техниканы җәлеп итү планнарын төзүне;

табигать янгыннарына бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү, торак пунктларны, икътисад һәм социаль инфраструктура объектларын урман янгыннарыннан саклау буенча эш итү гамәлләрен ныгыту, шулай ук урман янгыннарын һәм башка ландшафт (табигать) янгыннарын сүндерү өчен билгеләнгән көчләрнең һәм чараларның муниципальара эш итә белүе буенча комплекслы өйрәнүләр үткәрүне;

урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигать) янгыннары чыккан очракта, халыкка хәбәр итү һәм аны эвакуацияләү мәсьәләләрен җентекләп өйрәнүне;

янгын чыгу куркынычы чорында кешеләрне вакытлыча урнаштыру пунктларының эшләргә әзер булуын тикшерүне;

эвакуацияләнгән халыкның беренчел тормыш эшчәнлеген тәэмин итү планнарын эшләүне;

кешеләргә янгын чыгу турында хәбәр бирү чараларының тотрыклы эшләвен тәэмин итүне;

урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигать) янгыннары чыгу куркынычы янаганда һәм чыкканда «Югары дәрәҗәдә әзер булу» һәм (яки) «Гадәттән тыш хәл» дигән эш режимнарын үз вакытында кертүне тәэмин итүне;

торак пунктлар, шәхси йорт биләмәләре территорияләрен корыган үләннән һәм яна торган чүп-чардан үз вакытында чистартуны контрольдә тоту, шулай ук билгеләнмәгән урыннарда учаклар кабызуны рөхсәт итмәү өлешендә муниципаль берәмлекләрнең административ комиссияләре эшен активлаштыруны.

6. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына:

муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары белән берлектә, урман янгыннарын профилактикалауга һәм аларга каршы көрәшкә юнәлдерелгән оештыру-техник чаралар үткәрүне тәэмин итәргә;

урман массивларында һәм аларга якын урыннарда урнашкан табигый һәм ясалма сулыклардан янгын сүндерү техникасы белән су җыю мәйданчыкларын

төзекләндерүне дәвам итәргә;

урман янгыннарын башлангыч стадиясендә үз вакытында ачыклауга, локальләштерүгә һәм бетерүгә юнәлдерелгән оператив чаралар күрүне тәэмин итәргә;

урман янгыннарын сүндерү планнары нигезендә урман янгыннарын сүндерү өчен янгын сүндерү техникасын, транспорт чараларын, шулай ук юридик затларны һәм гражданнарны җәлеп итәргә;

республика җирле үзидарә органнарына торак пунктларның урман массивлары янындагы чикләре буйлап минераллаштырылган полосалар урнаштыруда ярдәм күрсәтергә;

янгын чыгу куркынычы сезоны башланганга кадәр:

билгеләнгән нормативлар нигезендә урман янгыннарын сүндерү формированиеләрен шәхси состав белән комплектлап бетерергә, шәхси составны өйрәтүне оештырырга;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт бюджет учреждениеләре карамагындагы урман янгыннарын сүндерә торган махсуслаштырылган техниканы һәм җайланмаларны техник яктан төзек хәлгә китерергә.

7. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына торак пунктларда һәм урман массивларында янгыннар чыгуны кисәтү максаты белән түбәндәге чараларны күрергә:

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карарын исәпкә алып, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм запас җирләрдә ачык ут куллану һәм учаклар кабызу тәртибен җиткерү буенча;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм алар янындагы урман массивларында язгы кыр һәм урып-җыю эшләрен башкарганда авыл хуҗалыгы оешмалары һәм фермер хуҗалыклары тарафыннан урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре үтәлешенә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру буенча;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә корыган үләннәрнең үсми торган урыннарын, урып алынган игеннәрнең җыелмый калганнарын, агач һәм куакларны бетерү буенча;

басуларның һәм торак пунктларның урман һәм торф массивларына, дала буйларына, автомобиль юлларына һәм тимер юлларга якын урнашкан урыннарын сөреп чыгу буенча;

авыл хуҗалыгы оешмалары территорияләрен чүп-чардан һәм корыган агачлардан чистарту, авыл хуҗалыгы формированиеләре балансындагы янгын сүндерү техникасы һәм янгын сүндерү өчен җайлаштырылган техника белән тәүлек буе кизү торуны оештыру (кирәк булганда), шулай ук төзек булмаган янгын сүндерү техникасын ремонтлау буенча.

8. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә һәм Россия Федерациясе

Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

2024 елның 29 апреленнән 13 маена кадәр урманнар һәм гражданнарның күпләп ял итү урыннары буйлап янгын куркынычсызлыгы таләпләре үтәлешенә патрульлек итүне;

халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары аша урман янгыннарына бәйле гадәттән тыш хәлләр янаганда һәм килеп чыкканда эш итү гамәлләре алгоритмы турында мәгълүмат җиткерүне оештыруны;

халык арасында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша, язгы-җәйге чорда торак пунктларда һәм урманнарда янгыннарны профилактикалау мәсьәләләре буенча максатчан юнәлештә эш оештыруны;

җыеннарда гражданнар белән янгыннарны сүндерү һәм гадәттән тыш хәл зонасыннан эвакуацияләнү буенча эш итү гамәлләрен өйрәнү дәресләрен үткәрүне;

урман янгыннарының һәм башка ландшафт (табигать) янгыннарының торак пунктларга һәм икътисад объектларына күчүе янаганда муниципаль, ведомство, хосусый һәм ихтыяри янгын формированиеләренең, урман янгыннарын сүндерү формированиеләренең әзерлеген, эш итү гамәлләрен кабатлап, тикшерүне оештыруны.

9. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына урман-парк зоналарына һәм гражданнарның күпләп ял итү урыннарына патрульлек итүне үткәрү чорында Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә һәм Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә законнарда каралган тәртиптә булышлык күрсәтүне тәкъдим итәргә.

10. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук «Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенә – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

янгын чыгу куркынычы сезоны башланганга кадәр төбәк һәм федераль әһәмияттәге автомобиль юлларына бирелгән полосаларны һәм аларны төзекләндерү элементларын янгыннан саклау буенча чаралар күрүне;

төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары кырыйларын, ян-як сөзәк урыннарын һәм аларга бирелгән полосаларын чүп-чардан, кирәкмәгән үлән һәм агач-куаклардан системалы рәвештә чистартып торуны тәэмин итүне.

11. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына:

язгы-җәйге чорда торак пунктларда һәм урманнарда янгын чыгудан саклану өчен үз-үзеңне дөрес тотуны пропагандалый торган видео һәм аудиороликлар эшләргә һәм аларны республика, шәһәр һәм җирле теле- һәм радиоканалларда («Татмедиа» акционерлык җәмгыяте филиалларында) трансляцияләүне оештырырга;

басма массакүләм мәгълүмат чараларында, халыкның үз-үзен имин тоту

кагыйдәләрен бастырып чыгарып, «Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы кисәтә» дигән профилактика рубрикасын оештырырга.

12. Балансына урман янгыннары чыгу куркынычына дучар балалар ялы һәм аларны савыктыру оешмалары кергән республика башкарма хакимият органнары, оешмалар җитәкчеләренә:

оешмаларның вазыйфаи затлары арасыннан янгын чыгуны үз вакытында ачыклау өчен патруль төркемнәрен оештырырга;

янгын чыгу турындагы мәгълүматны җирле үзидарә органнарына, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә бирү тәртибен эшләп бетерергә;

табигать (урман) янгыннары чыккан очракта, хәбәр итү һәм оешма территориясеннән балаларны эвакуацияләү тәртибен эшләп бетерергә.

13. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин